РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БОЛЬШЕАТРЯССКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗУР ӘТРӘЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 58-3-05, факс 58-3-05

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**12.11. 2020** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең Зур Әтрәч торак пунктында, гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча, гражданнар җыенын билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләр оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәләре, “Татарстан Республиксында җирле үзидарәләр турында”гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы “Зур Әтрәч авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә **КАРАР КЫЛАМ:**

1. 2020 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең Зур Әтрәч торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарылачак мәсьәләне раслау:

2.1. “Сез, 2021 елга түбәндәге эшләрне, ягъни:

- Авыл эчендәге юлларны ремонтлау;
- Суэтем каланчасына тирәнлек насосы сатып алу һәм урнаштыру;
- Зират территориясен төзекләндерү;
- Күл янындагы чишмә территориясен төзекләндерү эшләрен башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү өчен Бөек Ватан сугышында катнашучыарның тол хатыннары, балачактан инвалид, күп балалы гаиләләр һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан кала, Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең Никифоровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буларак теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан үзара салымга 1200 сум күләмендә акча җыелырга ризамы?

«РИЗА» «КАРШЫ»

2.2. «Сез, 2020 елга җыелган 21642 (егерме бер мең алты йөз кырык ике) сум күләмендәге акчаны “Зур Әтрәч торак пунктындагы балалар мәйданчыгы территорисен койма белән әйләндереп алу” һәм “Сугышта һәлак булганнар хөрмәтенә куелган обелиск территориясен төзекләндерү”дән “Авыл эчендәге юлларны ремонтлау”га күчерергә ризамы?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрү йөкләнелә.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы’’нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылган көненнән башлап үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Зур Әтрәч авыл җирлеге**
**Башлыгы** **И.Ш. Юнысов**